**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**ул. Советская, д.80,**
**с. Новошешминск,423190**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
**Совет урамы, 80,**
**Яңа Чишмә авылы,423190**

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
СОВЕТЫ карары

2020 елның 29 декабреннән — № 4-29

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 30.10.2017 ел, №30-175 карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 30.10.2017 ел, №30-175 карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

«Муниципаль хезмәткәрне һәм аның гаилә әгъзаларын пенсия белән тәэмин итү» турындагы 26 статьясындагы 26.4 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле җиденче, сигезенче абзацлар өстәргә:

"Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән затның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмаганда башкарыла.

Әлеге мәсьәлә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән соң 90 көн эчендә җайга салынганда, тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү шундый билгеләнеш сорап мөрәҗәгать иткән көннән башкарыла.»

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Интернет" мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» htt:/pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек итү комиссиясе рәисенә йөкләнә.

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башлыгы — В. М. Козлов